ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31.10.2025 ел Баулы шәһәре № 135

2026 елда Баулы муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны түләүсез туклану белән тәэмин итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнарының гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 ноябрендәге 1213 номерлы карары нигезендә, Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 16 августындагы 164 номерлы карары белән «Белем алулары Баулы муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары тарафыннан өйдә оештырылган сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучыларны ике тапкыр түләүсез туклану белән тәэмин итү тәртибен, шул исәптән ике тапкыр түләүсез туклануны акчалата компенсация белән алыштыру мөмкинлекләрен раслау турында» укучыларның аерым категорияләренә өстәмә социаль ярдәм чараларын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. 2026 елда бер тапкыр кулланыла торган түләүсез кайнар ризык белән тәэмин итәргә:

- бер үк вакытта Баулы муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында белем алучы 4 һәм аннан күбрәк бала тәрбияләүче күпбалалы гаиләләрдәге балалар;

- Баулы муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында белем алучы «Баулы муниципаль районында «Гаилә» балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приют» ДКУ балалары;

- Баулы муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында белем алучы инвалид балалар;

- махсус хәрби операциядән демобилизацияләнгән гражданнарның балалары.

2. 2026 елда ике тапкыр түләүсез кайнар ризык белән тәэмин итәргә:

- Баулы муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары тарафыннан өйдә белем алуны оештырган сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар;

- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, хәрби хезмәткәрләр һәм Россия Федерациясе Милли гвардиясендә хезмәт итүче затлар, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнар арасыннан махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның балалары, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләре, махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) югарыда күрсәтелгән категориядәге гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына).

3. Баулы муниципаль районының финанс-бюджет палатасына 2026 елда җирле бюджетны үтәү процессында гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны түләүсез тукландыруны тәэмин итүгә ташламалар бирү чараларына чыгымнарны каплауга финанс чаралары табарга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров